Reviews

Бәяләмә һәм күзәтүләр

Рецензии и обзоры

DOI: 10.26907/2311-2042-2022-19-2-182-188

# REVIEW OF ILGIZ KADYROV'S BOOK "TATAR WEDDING SONGS: THE SIBERIAN AREA" (KAZAN, 2021. 188 p.)

**Saviya Gimaltdynovna Samitova,**
Kazan National Research Technological University,
68 K. Marx Str., Kazan, 420015, Russian Federation,
savilas@yandex.ru.

The article reviews the book "Tatar Wedding Songs: The Siberian Area" (Kazan, 2021. 188 p.) by Ilgiz Kadyrov. The article provides information about the structure of the book, highlights the value and significance of the collection in the cultural life of the Tatar people. The book is based on the materials of Ilgiz Kadyrov's expeditions to the Tyumen, Tomsk, Omsk and Novosibirsk Regions of the Russian Federation in 1967–1973, to the regions where the Siberian Tatars live compactly. The book presents excellent examples of the Siberian Tatars' wedding songs not included in the folklore practice. The collection will be of interest to teachers and composers, as well as connoisseurs of Tatar folk music.

**Key words**: Siberian area, Tatar folk songs, wedding songs, culture

The G. Ibragimov's Language, Literature and Art Institute of the Tatarstan Republic Academy of Sciences published the book "Tatar Wedding Songs: The Siberian Area" [1]. For everyone who is not indifferent to the spiritual heritage of the Tatar people, it is a great achievement: the long-term work of Ilgiz Kadyrov, a national musicologist and an Honoured Worker of Culture of Tatarstan, has been published as a book. The scientific editor of the book is Ilsiyar Zakirova, Doctor of Philology, the chief researcher in the Department of Folk Art at the G. Ibragimov's Language, Literature and Art Institute; the computer notation of the songs has been carried out by Naila Nurgayanova, a senior researcher in the Arts Department of the same institute. Both experts took part in numerous scientific expeditions to the regions of Siberia where the Tatars live, studying their cultural heritage.

The book is addressed to folklorists and musicologists, teachers and students of higher and secondary educational institutions, to everyone who is interested in folk songs.

In 1967–1972, the Tatar musicologist and folklorist Ilgiz Kadyrov went on numerous scientific expeditions, collected and studied the samples of the Siberian Tatars' musical creative art. The scholar was interested in folk songs, performers, instrumental music and folk musical instruments. Ilgiz Kadyrov recorded folk melodies in accordance with all scientific requirements: he wrote

down who was the performer of each song, where he was born and lived, and added interesting information about his informants. The heritage of folk songs and music was recorded on audio cassettes. Later, Ilgiz Kadyrov repeatedly listened to these recordings, notated the melodies of the songs and deciphered the lyrics. The book consists of two large parts. The first part provides information about the history and ethnography of the Siberian Tatars. This part contains paragraphs about the history of collecting the Siberian Tatars' folk and wedding songs. The second part presents folk songs, performed during the wedding ceremony.

In the introductory part to the book, entitled "One Word", the author writes about his work: "I am a collector of musical and poetic creative works of the Siberian Tatars. In 1968–1977, while working at the G. Ibragimov's Institute of Language, Literature and History, I went on nine scientific expeditions to the Omsk, Tyumen, Novosibirsk, Tomsk and Kemerovo regions, and was lucky to record more than 500 songs and melodies with the aim of preserving them for science and people. This is our unique treasure".

All his life, Ilgiz abyi was interested in folk songs of the Siberian Tatars. He repeatedly returned to this music treasury, spoke on radio, television, in newspapers and magazines, at scientific conferences, trying to popularize them.

It should also be noted that these records represent unique findings; if the records were not preserved, it would be impossible to learn about them. The author was lucky to record Siberian songs on a tape recorder and to pass them on to our Siberian countrymen today – to the heirs of Khan Kuchum.

The article "Brief Historical and Ethnographic Information", included in the book and based on the works of historians, provides detailed and interesting information about the history of the Western Siberia Tatars, about the period of the Siberian Khanate, about the struggle of the Tatar people for the preservation of their statehood and their way of life. The articles, included in this part of the book, give an idea of the stages of the formation of the Siberian Tatars as an ethnonym-group, the boundaries of their territory. Ilgiz Kadyrov substantiates his observations with the works of the scientists who studied the Siberian Tatars: L. P. Potapova, S. V. Bakhrushin, V. V. Khramov, N. M. Yardintsev, N. F. Katanov, G. F. Miller, V. V. Radlov and D. G. Tumasheva. It is noteworthy that this collection, despite its profound scientific information, is written in a language accessible for the readers who are not experts in this field.

In the book "Tatar Wedding Songs: The Siberian Area", you can find answers to many questions about the Siberian Tatars. The article "The History of Collecting the Siberian Tatars' Folk Songs" highlights the activities of expeditions, which went to study the folklore and ethnography of the Siberian Tatars. The rich musical culture of the West Siberian Tatars, who constituted a significant ethnic group of the Tatar people, has not been sufficiently studied. Due to the fact that this region, as a cultural center of the Tatar people, is far from Kazan, real scientific work on the collection and study of musical folklore, especially the songs of the Tatars living outside Tatarstan, began only in the 1960s. It is known that in the pre-October works, there are very few materials reflecting the history, ethnography, language and folklore of this region. In this regard, Ilgiz Kadyrov highly appreciates the work of Academician V. V. Radlov "The Samples of Folk Literature of the Turkic Tribes" [2], calling it a unique source for studying the language and oral folk art of the Siberian Tatars. V. V. Radlov, who collected samples of folk art with great difficulty, was one of the first to convey the richness of the Siberian Tatars' spiritual culture to the whole world. In his book "The Samples of Folk Literature of the Turkic Tribes" [2], published in St. Petersburg in 1872, the scholar noted that those ancient melodies were preserved only in the memory of white-bearded old people and expressed concern about their possible loss in the near future.

Ilgiz Kadyrov did not fail to mention a single article, devoted to the songs of the Siberian Tatars. For example, in the article with the initials I. Yu., the world of the Siberian Tatars' music is described as follows: "Despite the fact that music is prohibited under Sharia law, the Siberian Tatars do not consider it a sin to sing a song from time to time, especially en route. On the one hand, they are right: their songs cannot be attributed to the musical sphere. They have no melody. The Tatars do not sing, their music stretches out monotonously like a road, and this song can last for ten kilometers. They sing about wide fields, an evil wife and a vigorous horse. In their songs, we can learn about the separation from a good father and about life in captivity" [1, p. 19].

The author highly appreciates the activity of the Tatar composer A. S. Klyucharov in this area. In addition, he dwells on the controversial issues related to the book "People's Pearls" by Jaudat

Fayzi [3]. He expresses his expert opinion on this matter.

It is necessary to mention another important aspect of the book. The lyrics, contained in this work, are reproduced with the preservation of the dialectal features of the Siberian Tatars' speech. The author comments on individual dialect lexemes. The texts with well-preserved dialectal features were translated into the literary language by the scientific editor, Doctor of Philology Ilsiyar Zakirova: at the end of the songs, additional stanzas in the literary language are given. This facilitates the perception of texts even for those who are not familiar with certain dialectal features. For example:

Turchainy iektem tus belen ei,
Ieltertem koskei pos pellen.
Peishembei aksham ash iskitsem,
Utyrtym matury kys belen.

*Turchainy zhiktem dus belen ei,*
*Zhildertem kozge bos belen.*
*Penzheshembe aksham ash ashadym,*
*Utyrdym matur kyz belen. [1, p. 130-131]*

A saddled little horse with a friend, oh[1]
Rushed when the autumn ice appeared.
Had dinner on a Thursday night,
Spent time with a nice girl.

In this sense, the work is significant in terms of lexicological research. The words that have gone out of use can be found in such songs as "Kiyau Tipsau", "Kuch Zhyry", etc. By the way, it is worth noting that the rites themselves are not practiced any longer, and no information about them can be found at present.

The collection includes 88 songs, united under the title "Wedding Songs". Many of these wedding songs are forgotten. The scholar's aim is to return these songs to the people, to breathe new life into the national melody. The songs, presented in the collection, refer to various stages of the wedding ceremony.

The song "Kiyau tipsau" is performed while seeing the groom off to the bride's house; "Ishek bavy" is sung at the meeting on the threshold of the bride's house; "Ai ellerlep kiyaune kergezu" or "Yaltyr aityu" can be heard at the stage of introducing the groom to the bride's house. The author recorded them in numerous versions from the Tatars of the Tyumen, Tobolsk, Sazan, Baraba, Tomsk and Kemerovo regions.

The author divides the songs, collected in the book, into the following groups: the songs of wedding ceremonies, the songs accompanying the bride and saying farewell to her, the songs performed with honors and praises of certain people, the songs performed while treating guests and the comic theatrical songs. The collection provides detailed information about the recording history of each song, about the regions in which it occurred, about the musical sound and lyrical tones, presenting numerous versions of the songs and notes for each version.

Even more interesting is the fact that the book is supplemented with photographs from I. Kadyrov's personal archive. This creates the atmosphere of that era; the photographs depict not only the informants of the last century, but also ethnographically interesting information.

In conclusion, I would like to say that on the one hand, this collection is a truly unexpected work; on the other, it is a long-awaited study. It is also symbolic that it was published in this way, as the language, music, culture and traditions of our people will never disappear. This book takes us back to the past, makes us think about how we speak our native language, how proud we are of our nation, how we preserve our national traditions.

**References**


1. Kadyrov, I. Sh. (2021). *Tatarskiye svadebnyye pesni: Sibirskiy areal* [Tatar Wedding Songs: The Siberian Area]. I. Sh. Kadyrov. 188 p. Kazan'. (In Russian)
2. Radlov, V. V. (1872). *Obraztsy narodnoi literatury tyurkskikh plemen, zhivushchikh v Yuzhnoi Sibiri i Dzungarskoi stepi. Narechiye barabintsev, tarskikh, tobol'skikh i tyumenskikh tatar* [Samples of Folk Literature of the Turkic Tribes Living in South Siberia and the Dzungar Steppe. The Dialect of the Baraba, Tara, Tobolsk and Tyumen Tatars]. St. Petersburg. (In Russian)
3. Fayzi, Z. (1971). *Narodnaya zhemchuzhina: fol'klor sovremennoi muzyki tatarskogo naroda: s notami i istoricheskimi kommentariyami* [Folk Pearl: Folklore of the Tatar People's Modern Music: With Notes and Historical Comments]. Z. Fayzi. 288 p. Kazan', Tatar. knizh. izd. (In Russian)


[1] We provide here a word for word translation of the recorded text.

# ИЛГИЗ КАДЫЙРОВНЫҢ «ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ТУЙ ҖЫРЛАРЫ: СЕБЕР АРЕАЛЫ» КИТАБЫНА (КАЗАН, 2021. 188 Б.) БӘЯЛӘМӘ

**Сәвия Гималтын кызы Сәмитова,**
Казан милли тикшеренү технология университеты,
Россия, 420015, Казан ш., К.Маркс ур., 68 нче йорт,
savilas@yandex.ru.

Мәкалә Илгиз Кадыйровның «Татар халкының туй җырлары: Себер ареалы» китабына (Казан, 2021. 188 б.) рецензия характерын йөртә. Мәкаләдә җыентыкның структурасы турында мәгълүмат бирелә, бу чыганакның татар халкының мәдәни тормышында кыйммәте һәм әһәмияте ассызыклана. Хезмәт И. Кадыйровның 1967-72 елларда Себер татарлары тупланып яшәгән төбәкләргә, Төмән, Томск, Омск, Новосибирск өлкәләренә чыккан экспедицияләренең материаллары буенча төзелгән. Хезмәттә себер татарларының хәзерге фольклор практикасыннан төшеп калган туй җырларының үрнәкләре урын алган. Җыентык педагогларга да, композиторларга да, татар халык музыкасын яратучыларга да кызыклы булачак.

**Төп төшенчәләр**: Себер ареалы, татар халык җыр фольклоры, туй җырлары, мәдәният

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында дөнья күргән «Татар халкының туй җырлары. Себер ареалы» китабын зур канәгатьләнү хисе белән укыдым [1]. Халык музыкасы белгече, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре Илгиз Кадыйровның күпьеллык хезмәтенең шул рәвешле китап булып укучыларга барып ирешүе татар халкының рухи мирасына битараф булмаган һәркем өчен шатлыклы яңалык булды. Җыентыкның фәнни редакторы Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы Илсөяр Закирова, җырларга комьютерда нотацияне шушы ук Институтның сәнгать бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре Найлә Нургаянова ясаган. Ике белгеч тә – Себернең татарлар яшәгән регионнарында күпсанлы фәнни экспедицияләрендә катнашкан, себер татарларының мәдәни мирасын өйрәнгән, бу турыда хезмәтләре белән билгеле галимнәр.

Китап фольклор һәм музыка белгечләренә, югары һәм урта уку йортлары укытучыларына һәм укучыларына, халык җырлары белән кызыксынучыларга адресланган.

Татар музыкасы һәм фольклор белгече Илгиз Кадыйров, 1967–1972 елларда күпсанлы фәнни экспедицияләргә чыгып, Себер татарларының музыкаль иҗатын туплый, өйрәнә. Галимне халык җырлары да, башкаручылар да, инструменталь музыка да, халык музыкасы уен кораллары да кызыксындыра. Автор-төзүче халык көйләрен бөтен фәнни таләпләргә туры китереп язып ала, һәр җырның башкаручысы кем булуын, аның кайда тууын һәм яшәвен генә түгел, ә информантлары турында кызыклы мәгълүматларны да теркәп бара. Халыкның җыр-музыка мирасы аудио тасмаларга теркәлә. Соңрак Илгиз Кадыйров бу язмаларны кат-кат тыңлап, җырларның көйләрен нотага сала, сүзләренә расшифровка ясый.

Китап зур ике өлештән тора. Беренче өлешендә Себер татарларының тарихы һәм этнографиясе турында мәгълүмат бирелә. Себер татарларының халык җырларын җыю тарихы һәм Себер татарларының туй җырлары турында параграфлар да шушы өлештә урнаштырылган. Икенче өлештә туй йоласы вакытында башкарыла торган халык җырлары бирелгән.

Автор китаптагы «Бер кәлимә сүз» дигән кереш мәкаләсендә үзенең эшчәнлеге турында: «Мин – себер татарларының музыкаль-поэтик иҗатын җыючы. 1968–1977 елларда, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшләгән дәвердә, Омск, Төмән, Новосибирск, Томск һәм Кемерово өлкәләренә тугыз фәнни экспедициядә булып, миңа шул экспедицияләр вакытында 500дән артык җыр һәм көйләр язып алу, аларны фән һәм халык

өчен саклап калу бәхете насыйп булды. Бу уникаль хәзинә» [1], – дип яза.

Илгиз абый Себер татарларының халык җырлары белән гомере буе кызыксына, бу хәзинәгә кат-кат әйләнеп кайтып, радио-телевидение һәм газета-журналлар аша, фәнни конференцияләрдә чыгышлар ясый, аларны популярлаштырырга тырыша.

Шунысын да әйтергә кирәк: әлеге язмалар уникаль байлык, чөнки борынгы халык җырларын, язмаларын бүген очрату да мөмкин түгел. Авторга Себер моңнарын магнитофонга язып алырга, һәм бүген аларны Себердә яшәүче милләттәшләребезгә – Күчем ханның варисларына тапшыру насыйп булды.

Китапка кергән «Кыскача тарихи-этнографик мәгълүмат» дигән мәкалә, тарихчы галимнәр хезмәтләренә таянып, Көнбатыш Себер татарларының тарихы, Себер ханлыгы чоры, татар халкының дәүләтчелеген саклап калу өчен көрәше, тормыш-көнкүреше турында тирән һәм кызыклы мәгълүмат бирә. Китапның бу өлешендә урын алган мәкаләләр Себер татарларның этноним-төркем буларак формалашу этапларын, территориясенең чикләрен күзалларга мөмкинлек бирә.

И. Кадыйров үз күзәтүләрен Себер татарларын өйрәнгән галимнәр Л. П. Потапов, С. В. Бахрушин, В. В. Храмова, Н. М. Ядринцев, Н. Ф. Катанов, Г. Ф. Миллер, В. В. Радлов, Д. Г. Тумашева фикерләре белән ныгытып бара. Шунысы игътибарга лаек: әлеге җыентык бик тирән фәнни мәгълүмат белән эш итүгә карамастан, бу өлкәдә белгеч булмаган укучылар өчен дә аңлаешлы телдә язылган.

«Татар халкының туй җырлары. Себер ареалы» китабында себер татарлары турында күп сорауларга җавап табып була. «Себер татарларының халык җырларын җыю тарихы» мәкаләсендә бу кавемнең фольклорын һәм этнографиясен өйрәнү максатыннан оештырылган экспедицияләрнең эшчәнлеге яктыртыла. Татар халкының шактый зур этник төркемен тәшкил иткән Көнбатыш Себер татарларының бай музыкаль мәдәнияте аз өйрәнелгән. Аның сәбәпләрен күрсәтеп, автор, бу регионның татар халкының мәдәни үзәге булган Казаннан ерак булуын, музыкаль фольклорны, бигрәк тә Татарстаннан читтәге өлкәләрдә яшәүче татарларның көй-җырларын чын-чыннан фәнни нигездә җыйнау һәм тикшерү эшләренең бары тик 1960 еллар тирәсендә генә юлга салынуын яза. 1917 елгы Октябрь революциясенә кадәр басылган хезмәтләрдә бу төбәкнең тарихы, этнографиясе, теле һәм фольклоры чагылдырылган материалларның бик аз булганлыгы мәгълүм. Бу яктан Илгиз Кадыйров академик В. В. Радловның «Төрки кабиләләренең халык әдәбияты үрнәкләре» хезмәтенә [2] югары бәя биреп, аны Себер татарларының телен һәм халык авыз иҗатын өйрәнү өчен тиңдәше булмаган чыганак, дип искә ала. Халык иҗаты үрнәкләрен зур кыенлык белән туплаган В. В. Радлов, беренче булып, Себер татарларының рухи культура байлыгын бөтен дөньяга җиткерә. Галим 1872 елда Санкт-Петербургта басылып чыккан «Төрки кабиләләрнең халык әдәбияты үрнәкләре» дигән китабында [2] борынгы көйләрнең бары тик ак сакаллы картлар хәтерендә генә сакланып калуын искәртә, якын киләчәктә аларның югалачагына борчылуын белдерә.

И. Кадыйров игътибарыннан себер татарлары җырларына багышланган бер генә мәкалә дә читтә калмый. Мәсәлән, И. Ю. инициаллары белән басылган мәкаләдә себер татарларының моң дөньясы түбәндәгечә яктыртылган: «Шәригать законнары буенча музыка тыелса да, Себер татарлары вакыт-вакыт, бигрәк тә юл йөргәндә, җыр сузуны гөнаһка санамыйлар. Бер яктан, алар хаклы да: аларның җырлавын музыка өлкәсенә кертергә берничек тә мөмкин түгел. Аһәңлелек законнары аларга бөтенләй ят нәрсә. Татар җырламый, ә бары тик бара торган юлы кебек озын һәм бертөрле итеп суза бирә, һәм җыр аңа тулы ун чакрымга җитә. Ул киң кырлар, усал хатын һәм көр аты турында җырлый. Аның җырында мәрхәмәтле әтисе белән аерылу һәм әсирлек турында ишетергә мөмкин» [1, б. 19 ].

Автор татар композиторы А. С. Ключаровның бу өлкәдә эшчәнлегенә зур бәя бирә. Шул уңайдан Җәүдәт Фәйзинең «Халык җәүһәрләре» китабы [3] белән бәйле бәхәсле мәсьәләләрне дә читләтеп үтми. Бу мөнәсәбәткә карата үзенең белгеч буларак фикерен җиткерә.

Китапның тагын бер әһәмиятенә тукталу кирәк. Бу хезмәттә урын алган җыр текстлары себер татарларының диалекталь сөйләм үзенчәлекләрен саклап бирелә. Автор аерым диалекталь лексемаларга аңлатма биреп бара. Диалекталь үзенчәлекләре яхшы сакланган текстлар хезмәтнең фәнни редакторы филология фәннәре докторы Илсөяр Закирова тарафыннан әдәби телгә күчерелеп, җыр ахырына өстәмә рәвештә әдәби телдәге строфалар да бирелә. Бу диалекталь

үзенчәлекләрне белмәгән кешегә дә, текстларны кабул итүне җиңелләштерә. Мәсәлән:

Турчайный йектем тус белән әй,
Йелтертем көсгей пос пеллән.
Пәйшәмбеи акшам аш искицем,
Утыртым матуры кыс белән.

*Турчайны җиктем дус белән әй,*
*Җилдердем көзге боз белән.*
*Пәнҗешәмбе акшам аш ашадым,*
*Утырдым матур кыз белән* [1, б. 130–131].

*(Турчай – кечкенә ат)*

Бу яктан хезмәт лексикология кысаларында да әһәмияткә ия. Көндәлек кулланылыштан күптән төшкән сүзләрне әлеге җыентыкта урын алган «Кияү типсәү», «Күч җыры» һәм башка җырларда очратырга мөмкин. Сүз уңаеннан шуны да әйтеп китү урынлы булыр: бу йолалар үзләре дә әйләнештән төшеп калган, хәзерге вакытта алар турында мәгълүмат табып булмый.

Җыентыкта «Туй җырлары» атамасы астында 88 җыр тупланган. Әлеге туй җырларының күбесе – онытылган җырлар. Галимнең максаты – бу җырларны яңадан халыкка кайтару, милли моңга яңа сулыш өрү. Җыентыкта урын алган җырлар туй йоласының төрле этапларына карый.

Кияүне кыз өенә озаткан вакытта башкарыла торган «Кияү типсәү», кыз йортының капкасында каршы алган вакытта «Ишек бавы», кияүне кәләш янына кертү этабында «Ай әллерләп кияүне кергезү» яки «Ялтир әйтү» һәм башка йолалар вакытында башкарыла торган җырларны автор Төмән, Тубыл, Саз ягы, Бараба, Томск һәм Кемерово өлкәләрендә яшәгән милләттәшләребездән күп санлы вариантларда язып ала.

Автор китапта тупланган җырларны түбәндәге төркемнәргә бүлә: туй йолалары җырлары, кыз озату һәм аның белән хушлашу җырлары, аерым кешеләрне зурлап һәм мактап башкарыла торган җырлар һәм кунакларны сыйлаган вакытта башкарыла торган җырлар, шаян, театральләшкән җырлар. Җыентыкта урын алган һәр җырның язып алыну тарихы, кайсы төбәкләрдә очравы, музыкаль яңгырашы һәм лирик төсмерләре турында тәфсилле информация бирелә, җырларның күп санлы вариантлары, һәр вариантның ноталары тәкъдим ителә.

Китапның И. Кадыровның шәхси архивыннан алынган фотосурәтләр белән баетылуы, аны тагын да кызыклырак итә. Бу шул чор атмосферасын тудыра, фотоларда узган гасырның информантлары гына түгел, этнографик яктан кызыклы мәгълүмат та саклана. .

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: бу җыентык, чын мәгънәсендә, бер яктан - көтелмәгән, икенче яктан - көтеп алынган хезмәт. Аның нәкъ менә шушы калыпта басылуы да символик мәгънәгә ия – халыкның теле, көе-моңы, мәдәнияте, традицияләре беркайчан да югалмаячак. Бу китап безне яңадан туган телебездә тартынмыйча сөйләшкән, милләтебез белән горурланган, милли гореф-гадәтләребезне саклаган үткәнебезгә алып кайта, уйланырга мәҗбүр итә.

**Әдәбият**


1. *Кадыйров И. Ш.* Татар халкының туй җырлары: Себер ареалы. Казан, 2021. 188 б.
2. *Радлов В. В.* Образцы народной литературы тюркских племен, живущих в Южной Сибири и Дзунгарской степи. Часть IV. Наречия барабинцев, тарских, тобольских и тюменьских татар. СПб., 1872.
3. *Фәйзи Җ.* Халык җәүһәрләре: татар халкының хәзерге заман музыка фольклоры: ноталар һәм тарихи аңлатмалар белән. Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. 288 б.


# РЕЦЕНЗИЯ НА КНИГУ ИЛЬГИЗА КАДЫЙРОВА «ТАТАРСКИЕ СВАДЕБНЫЕ ПЕСНИ: СИБИРСКИЙ АРЕАЛ» (КАЗАНЬ, 2021. 188 С.)


**Савия Гималтыновна Самитова,**
Казанский национальный исследовательский технологический университет,
Россия, 420015, г. Казань, ул. К. Маркса, д. 68,
savilas@yandex.ru.



Статья носит характер рецензии на книгу Ильгиза Кадыйрова «Татар халкының туй җырлары: Себер ареалы» («Татарские свадебные песни: Сибирский ареал» (Казань, 2021. 188

с.). В ней приводятся сведения о структуре книги, подчеркивается ценность и значение сборника в культурной жизни татарского народа. Книга составлена по материалам экспедиций Ильгиза Кадыйрова в Тюменскую, Томскую, Омскую, Новосибирскую области РФ в 1967–1973 гг., в те регионы, где компактно проживают сибирские татары. В книгу включены ярчайшие образцы свадебных песен сибирских татар, ныне ушедших из фольклорной практики. Сборник будет интересен как педагогам и композиторам, так и ценителям татарской народной музыки.

**Ключевые слова:** Сибирский ареал, татарский народный песенный фольклор, свадебные песни, культура.